СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №142 (7441) | 28 ноябрь, 1992 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

**Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы КАРАРЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ УНИКЕНЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ЮГАРЫ СОВЕТЫНЫҢ XIV СЕССИЯСЕН ЧАКЫРУ ТУРЫНДА**

Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Югары Советының XIV сессиясен 1992 елның 21 декабрендә Казан шәһәрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. МӨХӘММӘТШИН.**

## Җитди сөйләшү булды

25 ноябрьдә район администрациясе бинасының кече залында киңәшмә үтте. Анда район потребительләр җәмгыяте, эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре җитәкчеләре һәм сәүдә предприятиеләре вәкилләре, банк һәм районның башка финанс службалары җитәкчеләре катнаштылар. Киңәшмәгә шулай ук икенчел чимал әзерләү, урман промышленносте хуҗалыгы һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе җитәкчеләре дә чакырылды.

Районның сәүдә тармагының социаль-экономик үсеше мәсьәләсе буенча район администрация башлыгының экономика һәм прогнозлау буенча урынбасары Р. Ф. Җамалиев чыгыш ясады.

Аның чыгышында тармак эшчәнлегенең уңай яклары белән бергә илнең гомуми экономик тотрыксызлыгыннан бәйле булган кимчелекләр, җитешсезлекләр дә ачылды. Иптәш Җамалиев үз чыгышында шулай ук банк службалары, аларның сәүдә тармагы белән үзара бәйләнеше мәсьәләләренә дә кагылды.

Тикшерелгән мәсьәлә буенча агропромбанк управляющие А. М. Фадеев, төзелеш банкы управляющие Ф. И. Мәҗитов, Октябрь райпосы рәисе М. С. Моратов, районара сәүдә базасы директоры И. С. Сафиуллин, азык комбинаты директоры Ф. Н. Гобәйдуллин, налог инспекциясе начальнигы И. К. Дәүләтшин, көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе директоры урынбасары Р. Р. Азюкова иптәшләр фикерләрен белдерделәр.

Киңәшмәдә катнашучылар алдында йомгаклау сүзе белән район администрациясе башлыгының беренче урынбасары Ф. М. Галимов чыкты.



## Районда Россия Федерациясе хосусыйлаштыру чекларын тарату дәвам итә

***Иптәш! Син үз чегыңны алырга онытмадыңмы? Исеңә төшерәбез: аны бирү 1992 елның 31 декабрендә төгәлләнәчәк.***



### *3 декабрь—халыкара инвалидлар көне*

## Шәфкатьлелек кирәк

**Берләшкән милләтләр оешмасы Генераль Ассамблеясының 47 нче сессиясе карары нигезендә 3 декабрь —халыкара инвалидлар көне итеп билгеләнде.**

26 ноябрь көнне район администрациясе бинасында үткәрелгән киңәшмәдә нәкъ шушы көнне тиешле югарылыкта үткәрү турында сүз барды. Район администрациясе башлыгы урынбасары А. И. Газизуллин киңәшмәне ачып, әлеге категория кешеләренең бүгенге шартларда аерата игътибарга мохтаҗ булуларын ассызыклады. Район администрациясе башлыгының беренче урынбасары Ф. М. Галимов районда әле бу категория кешеләргә ешкына битарафлык, ваемсызлык очраклары белән очрашырга туры килүенә конкрет мисаллар китерде. Бу көнне оешкан төстә үткәрергә, беркемне дә игътибардан читтә калдырмаска кирәклеген ассызыклады.

Район социаль-тәэминат бүлеге мөдире Л. Н. Дилмөхәммәтова районда 3 меңгә якын инвалид исәпләнүен белдерде. Бу көнне тумыштан гарип инвалид балаларга (алар 300 дән артык) аерата җылылык соралуын әйтеп, аларның аналары өчен оешма-предприятиеләргә аерым льготалы шартлар тудырырга киңәш итте. Шулай ук Совет Армиясе инвалидларының (алар 27әү) яшәү шартлары белән дә һәрдаим якыннан кызыксыну, ярдәм булырга тиешлегенә басым ясады.

Киңәшмәдә районда сукырлар җәмгыяте рәисе Ф. Н. Хаҗиморатов, район финанс бүлеге мөдире Р. Г. Билалов та чыгыш ясадылар.

Киңәшмәдә 3 декабрьгә кадәр районда инвалидларны барлау, аларның яшәү шартларын, ихтыяҗларын ачыклау һәм тиешле ярдәмне оештыру максатында һәр оешма-предприятиедә махсус штаблар яки комиссияләр оештыру, инвалидлар көнен шулай ныклы әзерлек белән игътибарлылык, шәфкатьлелек шартларында үткәрү зарурилыгына басым ясалды.

## Ярдәмләшеп эшлиләр

Сөт җитештерү, аны дәүләткә сату планнарын үтәүдә «Татарстан» колхозы терлекчеләре тырыш хезмәт итәләр. Хәзер терлекләрне кышлату чоры бара. Маллар җылы, коры абзарларда асрала, азык та җитәрлек. Агымдагы елның 10 аенда дәүләткә 8554 центнер сөт сатылды. Хәзергесе көнгә колхозда бер сыердан уртача 8,3 килограмм сөт савалар. Бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 1,8 килограммга артык. Бу —терлекчеләрнең олы хезмәт нәтиҗәсе. Биредә азык цехында азыклар төрле кирәкле элементлар белән баетыла, рацион тулы балансланган. Савучыларның нормаль хезмәте өчен шартлар да бар. Алар үзара ярышып, ярдәмләшеп эшлиләр. Бүгенге көнгә күрсәткечләр буенча Гөлчәчәк Вазыйховна Насыйбуллина алда бара. Аның карамагындагы һәр сыер 10 айда 3321 әр килограмм сөт бирде. Хезмәттәшләре Тәнзилә Кәлимулловна Нуруллина группасында бу күрсәткеч 3289 килограмм, Әлфия Мөниповна Сәлахова группасында 3190 килограмм тәшкил итте. Әнә шулай савучылар кышлатуны әйбәт күрсәткечләр белән үткәрүгә нык исәп тотып эшлиләр.

**Г. ГАФИЯТУЛЛИНА.**

## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

### Сәяхәттә булдылар

**Яшь туристларның район станциясе.** Ноябрь ае яшь туристлар өчен экскурсия-сәяхәтләргә бай булды. Станция линиясе буенча шәһәр мәктәпләреннән 5 группа Санкт-Петербург шәһәрендә булып кайттылар. Көзге каникул көннәрендә 8 группа—нигездә туган якны өйрәнү түгәрәкләренә йөрүче укучылар—Колбай Мораса авылы музее белән таныштылар, 2 группа Болгар шәһәренә барып тарихи урыннарны күреп кайтты. Моннан тыш 6 группа укучылар шәһәр буенча танышу-карау экскурсиясендә булдылар. Әлеге сәяхәтләр укучыларда туган якка мәхәббәт, аның тарихына, үткәненә ихтирамлы караш тәрбияләүгә исәпләнгәннәр.

### Тегәләр дә, саталар да

Быел станция каршында туристлар кирәк-яраклары тегү һәм ремонтлау буенча түгәрәк эшли башлады. Хәзергә ул 2 юнәлештә эшли: бер группа укучыларга машина белән эш итү, тегү күнекмәләре бирелсә, икенче группа инде продукция җитештерергә җыена. Түгәрәк җитәкчесе А. Хаҗиморатова кул астында балалар кухня пәрдәләре, салфеткалар тегәләр, аны реализацияләүдән кергән акчаның 28 проценты балаларга түләнәчәк.

**Р. ИБРАҺИМОВА.**

## Ишеттегезме әле...

**ШТРАФ КҮЛӘМЕ АРТТЫРЫЛДЫ**

Ноябрь башыннан алып Түбән Кама шәһәрендә пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен штраф алу күләме нык арттырылды. Хәзер шәһәр һәм шәһәр тирәсе юлларында йөри торган автобусларга, шулай ук маршрут таксиларына билетсыз утырган кешегә 50 сум штраф салына, ә багаж өчен түләмәгән булсаң, тагын 25 сум өстәргә кирәк була.

⊙ ⊙ ⊙

**ФЕРМЕРЛАРНЫҢ УҢЫШЫ**

Хәзер Татарстан Республикасында 557 фермер хуҗалыгы бар. Аларның шактый өлеше быел яхшы нәтиҗәләргә ирешә.

Күптән түгел фермерлар И. Байтимеров һәм В. Кинотяның хуҗалык утарында (ә ул Бөгелмә районының Березовка авылында урнашкан) өр-яңа зур йөк машинасы пәйдә булды. Мәгълүм булганча, хәзер мондый техника бик кыйбат тора. Әмма крестьяннар бу машинаны акчага түгел, ә авыл хуҗалыгы продукциясенә алыштырып алдылар. Әлеге яшь фермерларның гаиләләре быел үзләренең 40 гектарлы җирендә әйбәт уңыш үстерделәр.

Бодайдан, арпа, бәрәңге һәм карабодайдан югары уңыш алу белән бергә, бу яшь фермерлар бер гектар мәйданда шикәр чөгендере чәчкәннәр иде. Аннан 20 тоннага якын уңыш җыеп алындылар. Татлы тамырны югалтуларсыз Зәй шикәр заводына илтеп тапшырдылар.

**Татарстан яңалыклар агентлыгы (ТАН).**

# Кремль фетнәсе

**(Ахыры. Башы 2 биттә).**

дый хәл була калса, үз үзен атып үтерергә ният ләгәндер. Телефон аша ул аңа нәкъ шулай диде дә: «Синнән башка бер минут та яшәмәячәкмен».

Ул кичне без дә Пугоны төнлә кулга алырлар дип уйладык. Шунлыктан ирем аларга төн кунарга дип китте, авыр минутларда этисе янында буласы килде...»

**В. Пуго сөйләгәннәрдән:**

«...21 август кичендә эти һәм әни безгә килделәр. Табын әзерләдек, шәраб эчтек. Хатын-кызлар бик борчылыштылар, еладылар. Ә эти аларны тынычландырды, «бөтенесе дә нормаль, мин Горбачевны каршыларга барам»,—диде.

Бер рюмка шәраб эчте. Кәефе әйбәт иде. Тагын бераз утырганнан соң әни өйгә кайтып китте, ә эти минем янга килде дә, кочаклап алып, болай диде: «Бөтенесе дә бетте—минем хөкүмәт телефоннарын өзделәр, прокуратура җинаять эше кузгатты». Ничек инде син, эти, шундый сак кеше, ялгыша алдың, дип сорадым. Ә ул моны үзенең дә аңлый алмавын, нин-дидер «кара эшкә кереп бату»ын әйтте.

Иртән, эшкә барыр алдыннан, мин эти янына кердем һәм аның нидер язып утырганын күрдем. Үлем алдыннан записка язуы булган икән. Мин сине бүген күрә алырмыны әле, дип соравыма ул: әйе, кичен күрешербез, диде. Коридорда әнине очраттым. Ул бик боек иде, елап та куйды.

...Аларның атылып үлүен миңа әниемнең этисе—бабам хәбәр итте».

Тикшерү 22 август иртәсендә Борис Карлович Пуго карамагында «вальтер» пистолетыннан ике тапкыр атуларын ачыклады. Икесен да Пуго аткан: башта хатынына, аннары үзенә. Медицина экспертларының әйтүенчә, үз-үзен атканнан соң Пуго әле 10—20 минут яшәгән.

Валентина Ивановна да язу язып калдырган: «Кадерлеләрем минем! Бүтән яши алмыйм. Безне гаепләмәгез. Бабагыз турында кайгыртыгыз. Әниегез».

**(«Огонек», №38—39. 1992 ел).**

# Йокыгыз тынычмы?

«Өйдә җылы булганда—яшисе килә!»—диләр еш кына ялгыз әбиләр үзара сөйләшкәндә. Бу фикер белән килешми мөмкин түгел. Әгәр яши торган йортыгыз үзәк җылылык системасына тоташтырылган булса бигрәк тә. Мич ягасы, ягулык табасы юк.

Хәзерге вәкытта җылылык челтәре хезмәтеннән Шашин, Северная, Киевская, Чехов, Нефтьчеләр, Синдряков, Совет, Мир, Дружба», Космонавтлар, Победа урамнарында шәхси йортларда яшәүчеләр дә файдалана. Әмма җылылык энергиясеннән файдалану җылылык челтәре һәм куллаучылар (абонентлар) арасында килешү нигезендә башкарылырга тиешлеген аерым басым ясап әйтәсем килә. Җылылык челтәренә үз белдекләре белән тоташтырылган йорт хуҗалары кулланылган җылылык энергиясенең бәясен биштәтә күләмдә түләргә тиешләр.

Җылылык челтәренең бүлену чигеннән соң җылылык энергиясенең барлык чыгымнары куллаучы хисабына туры килә. Икенче төрле әйткәндә: түләү өчен исәп-хисап ясаганда җылылык трассасы белән җылытыла торган объект арасы да, үткәрелгән торбаның диаметры, җылытыла торган бинаның мәйданы да исәпкә алына.

Кызганычка каршы, җылылык челтәренең бүгенге көндәге куәте барлык теләүчеләрнең дә үтенечен канәгатьләндерә алмый. Шуңа күрә энергиянең бу төрен сарыф итүгә мөмкин кадәр саграк карарга кирәк. Әмма чынлыкта шуның киресе белән еш очрашабыз. Җылылык челтәреннән су алу аеруча зур бәла булып тора. Фатирлар буенча күпме йөрсәк тә, халыкка күпме аңлатсак та җылылык трассасыннан кайнар су алудан туктаганнары юк. Батареяларда краннар һәркайда бар.

Шәхси йорт хуҗалары белән аңлашу аеруча кыен. Бигрәк тә Шашин урамында яшәүчеләр белән. Бөтен кагыйдәләрне бозып, тиешле килешүләр төземәстән генә, монда түләүсез-нисез мунчаларын, гаражларын, идән асларын, теплицаларын һәм башка ярдәмче биналарын җылытып яталар. Ә бу исә энергиядән үз белдекләре белән файдаланалар дигән сүз.

Болар бит ялгыз карчыклар түгел (алары, кагыйдә буларак, соңгы тиеннәрен биреп булса да, дәүләт белән исәп-хисапны өзәргә ярталар), боллар—мохтаҗлыкны белмәүче, тормыштан зарланыр урыннары булмаган һәм үзләренең бу гаепләрен кесә такыр булуга сылтый алмаучылар, иркен, мул яшәүчеләр.

Бу юлы без аларның исемнәрен бөтен халыкка игълан итмәскә дигән фикергә килдек. Бәлки шушы мәкалә алар өчен соңгы кисәтү булыр дип өметләнәбез. Чөнки җылылык энергиясеннән үз белдекләре белән явыз ниятгә файдаланучыларга штраф бирелә, ә ел дәвамында алар икенче тапкыр шуны ук кабатласалар —җинаять җаваплылыгына тартылачаклар. Закон буенча 2 елга кадәр вакытка иректән азат итү яки шул ук срокка төзәтү эшләре, яки зур күләмдә штраф бирү каралган (РСФСР Җинаятьләр Кодексының 942 һәм административ хокук бозулар турында Кодексның 951 маддәләре).

Административ яки җинаять җәзасы кулланылуга карамастан закон бозучылар китерелгән зыян өчен (җылылык трассасына ялгаганда линияне, аның арматурасын бозу яки башка шундый очракларда) материаль җаваплылыкка да тартылалар.

Килешү төзү һәм җылылык энергиясеннән файдалану өчен тиешлесен түләү күпкә җиңелрәк түгелмени соң? Тыныч күңел белән йокы да тынычрак була бит, беләсезме?

**Н. ГАВРИЛОВА,**
җылылык челтәре инспекторы.

# Тормышка матурлык аша

«Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең «Әкият» ясле-бакчасы 1986 елда ачылган иде. Шул вакыттан бирле ясле-бакча коллективы балаларны әхлакый-эстетик тәрбияләү буенча максатчан эш алып бара.

Педагоглар эстетик тәрбия бирүне төрле юнәлешләрдә үткәрергә омтылалар. Чөнки алар бу тәрбияне баланың һәр яклы үсешендә аерылгысыз бер өлеш дип карыйлар.

Бу учреждениедә балаларның гармоник үсеше өчен барлык шартлар да тудырылган: музыка һәм физик культура белән шөгыльләнү өчен заллар, сынлы сәнгать һәм кул хезмәте кабинеты бар. Барлык кабинетлар кирәкле әсбаплар, дидактик уеннар, техник чаралар белән җиһазландырылган.

Балаларга эстетик тәрбия бирүдә учреждение бинасының эчке бизәлеше дә зур мәгънәгә ия. Коллектив бинаның эчен бизәүдә педагогик таләпләрне һәм заманча дизайнны истә тотып эшләгән.

Бизәлешнең әледән-әле үзгәреп торуы да балаларда гадәти әйберләрнең матурлыгын күрү сыйфаты тәрбияли. Балаларны декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре аеруча җәлеп итә. Монда агачны уеп, гипстан, мозаика ысулы белән, табигый материалдан (пычкы чүбе, агач кабыгы, таш), чәчәкләр һәм яфраклардан композицияләр киң кулланылган.

Балаларда эстетик хисләрне үстерүдә табигатькә зур урын бирелгән. Шуңа күрә дә «Аланлык» дип аталган табигать почмагын ясаганда тәрбиячеләр балаларга анда нәни хуҗалар буларак катнашырга мөмкинлек калсын өчен тырыштылар. Монда һәр деталь зәвык белән урнаштырылган. «Аланлык»та күп кенә бүлмә гөлләре үсә. Шунда ук әрләннәр, попугайлар, ташбака, керпе бик тату яшиләр, балыклар да бар. Кирәкле әдәбият, белешмәләр тупланган, түгәрәкнең расписаниесе, эш планы бар. Сүз уңаеннан әйтик, мондагы тәрбиячеләр беренче булып түгәрәк эшен башлап җибәрделәр. Өлкән группа балалары үзләрен кызыксындырган түгәрәкләрдә шөгыльләнәләр. Мәсәлән, «Бал корты» түгәрәгендә алар кәгазьдән, тукымадан, табигый материалдан әйберләр ясарга, макраме үрергә өйрәнәләр, ә «Салават күпере» студиясендә яшь рәссамнар бик теләп шөгыльләнә. Теләүчеләр өчен «Батыр» дип исемләнгән физкультура түгәрәге эшли, музыкаль-театраль түгәрәк тә бар.

Балалар бу түгәрәкләрдә һөнәргә өйрәнеп кенә калмыйлар, үзләренең шәхси үсешләре өчен этәргеч тә алалар.

Бу түгәрәкләргә үзләрендә дә иҗатка омтылыш зур булган тәрбиячеләр җитәкчелек итә. «Аланлык» түгәрәге җитәкчеләре Н. В. Сакаева һәм С. А. Жемкова балаларны гаҗәеп табигать дөньясы белән таныштыралар. «Салават күпере» изостудиясендә тәрбиячеләр Э. Э Арсланбекова, А. И. Хисмәтуллина һәм Х. Г. Вәлиуллина балаларны табигатьтән алган тәэсирләрен кәгазьгә төшерергә өйрәтәләр. Кул хезмәте түгәрәгендә С.В. Виссарионова осталыкка өйрәтә. Л. И. Сергеева карамагында балалар борынгы зирәкләр уены—шахмат серләренә төшенәләр. Балалар шахмат хикмәтләрен әкият һәм хикәяләр укып, рәсемнәр карап өйрәнәләр, үзләре дә игътибарлылык, көндәшлек рухы тәрбиялиләр, хәтерләрен ныгыталар, тапкырлыкка, уйларга, вакытны төгәл исәпли белергә өйрәнәләр.

Һәм, ниһаять, «Батыр» секциясен спорт энтузиастлары И. С. Васильева һәм Р. Р. Кыямова җитәклиләр.

Бу эштә күп нәрсә педагогның шәхесенә, аның кызыксынучанлыгы һәм иҗади мөмкинлекләренә бәйле. Алар үзләренең эшен кирәкле һәм мавыктыргыч итеп саныйлар, ул балаларга да, өлкәннәргә дә канәгатьлек бирә, нинди дә булса эшчәнлек белән ныграк кызыксынуга һәм тытызрак аралашуга ярдәм итә. Ә эшнең нәтиҗәләре—күз алдында: алар— группа бүлмәләренең эчке бизәлешендә чагыла. Моннан тыш балалар нәниләр өчен уенчыклар, эти-әниләренә бүләкләр ясыйлар, концерт-тамашалар күрсәтәләр, «Аланлык»тагы үсемлекләр һәм җан ияләре турында кайгырталар. Педагоглар балалар белән ата-аналарның уртак иҗатына зур әһәмият биреп өлкәннәрне дә түгәрәкләр һәм студияләр эшенә тартырга тырышалар. Узган уку елында алар эти-әниләрне, шәһәрнең ясле-бакча тәрбиячеләрен түгәрәкләр эше белән таныштырдылар. Ә соңгылары исә үз чиратларында бу башлангычка югары бәя бирделәр.

**Р. ХӘСӘНШИНА,**
район халык мәгарифе бүлегенең мәктәпкәчә тәрбия буенча инспекторы.




**Норлат шәһәрендә яшәүче әниебез Җәвидә Кирам кызы Хәбибуллинаны туган көне белән котлыйбыз. Корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, шатлык, бәхетле көннәр телибез.**

**Күп эшләдең, авырлыклар күрдең.**
**Ләкин бирешмәдең: нык булдың.**
**Сәламәт бул, әни, озак яшә,**
**Озын булсын гомер юлларың,**
**Иң изге теләкләр белән кызларың,**
**кияүләрең, оныкларың.**

**«Комбайн» колхозы идарәсе, профсоюз комитеты МОСТАФИДӘ ХАҖИ кызының үлүе сәбәпле, Фәтхетдиновлар гаиләсенең, якыннарының, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.**

**Мөхәррир урынбасары Р. З. АЙЗАТУЛЛИН**

**Учредительләр: редакциянең хезмәт коллективы һәм халык депутатларының Октябрь районы Советы.**

**Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—14, 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм Советлар тормышы бүлеге 2—10—44, рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; авыл хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51, җаваплы секретарь, хатлар, массалар белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2—18—67; фотокорреспондент 2—15—63.**

**Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2-10-54.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Нина ТОЛМАЧЕВА верстка ясады. Наташа ЛУКОЯНОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА.**
**Күләме—1 басма табак.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.**

**Тираж 3751.**
**Заказ 142.**